РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№ 29

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Арташ авыл җирлеге Советының
26.11.2019 елгы 27 номерлы «Саба муниципаль
районының Арташ авыл җирлеге
территориясендә җир салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә һәм федераль законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге Советы

карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 26.11.2019 ел, №27 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 нче пунктта 1.2.2 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.2. торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләрен һәм аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләрен;»;

1.2. 1.2 нче пунктта 1.2.3 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.3. шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шулай ук "гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, моңа

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләренең әлеге абзацында;».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/artash адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Арташ авыл җирлеге Башлыгы Р.И.Мөхәрләмов